**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.06.2024 № ПР-100 №____

«Сабантуй - 2024» татар халык бәйрәмен уздыру турында

«Сабантуй» татар халык бәйрәмен уздыру турында» 2024 елның 05 мартындагы 173 номерлы Татарстан Республикасы Рәисенең Указын үтәү йөзеннән, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Сабантуй - 2024» татар халык бәйрәмен әзерләү һәм үткәрү буенча район комиссиясе составын 1 нче кушымта нигезендә расларга;

2. Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына:

2.1. Бәйрәм уздыру урыннарында сәүдә нокталарының урнашуын билгеләргә, аларның эшен тәэмин итәргә;

2.2. Районның төп магистральләрендә, шулай ук бәйрәм үткәрелү урыннарында урнашкан сәүдә һәм кулланучылар хезмәтләре объектларын сәнгати һәм тематик бизәү эшләрен оештырырга, әлеге объектлар җитәкчеләренә үз сәүдә нокталары янында каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар урнаштырырга һәм бәйрәм тәмамланганнан соң җыештыруны тәэмин итәргә;

3. Башкарма комитетның эшләр идарәчесенә майданда һәм аның тирәсендәге территорияләрдә бәйрәм чаралары уздыру урыннарын төзекләндерүне тәэмин итәргә.

4. Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына мәдәни-массакүләм һәм спорт чаралары уздыруны, мәйданны сәнгатьчә бизәүне тәэмин итәргә.

5. Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына, финанс-бюджет палатасы рәисенә расланган смета нигезендә тапшырылган счетлар өчен түләргә.

6. Тәкъдим итәргә:

6.1. «Коммунсервис» МУП директорына Башкарма комитет эшләре идарәчесе белән берлектә майданда һәм аның тирәсендәге территорияләрдә бәйрәм чаралары уздыру урыннарын төзекләндерүне тәэмин итәргә;

6.2. Башкарма комитетның икътисад, эшләр идарәчесе, социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына район Советы һәм Башкарма комитетының тармак бүлекчәләре, ведомство буйсынуындагы учреждениеләр, предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләре белән берлектә районның бәйрәм бизәлеше һәм бәйрәм үткәрү урыны буенча эшләр башкаруын шәхси контрольгә алырга;

6.3. Районның үзәк магистральләрендә урнашкан сәүдә, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәт күрсәтү предприятиеләре һәм башка оешмалар җитәкчеләренә фасадларны, элмә такталарны, витриналарны бизәргә, рекламаның яктылык режимын, объектларның эчке интерьерларын төзекләндерү кагыйдәләре таләпләренә туры китерергә;

6.4. Оештыру-хокук формаларына һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, район предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары җитәкчеләренә бәйрәм чараларын финанслауда өлешләп катнашырга; «Сабантуй-2024» татар халык бәйрәмен

әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашырга, планнар нигезендә эшләрне башкаруны оештырырга;

6.5. Актаныш янгын-коткару гарнизоны башлыгына бәйрәм уздырыла торган урыннарда янгынга каршы чараларны үтәүне тәэмин итәргә;

6.6. Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручыга җәмәгать тәртибен саклауны, мәйдан янындагы чатыр формаларын, өйләрне, конструкцияләрне саклауны, татар халкының «Сабантуй-2024» бәйрәмен үткәргәндә монтажлау һәм сүтү чорына бәйрәм бизәлешен тәэмин итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына __ _______ 2024ел №___
1 нче кушымта

**«Сабантуй-2024» татар халык бәйрәменә әзерлек һәм аны уздыру буенча район комиссиясе составы***

Р.А. Ильясов -комиссия рәисе, Башкарма комитет җитәкчесе;

И.И.Габдулхаев -комиссия рәисе урынбасары, район Башлыгы урынбасары;

М.З.Гыйлаева - комиссия секретаре, Актаныш муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы.

**Комиссия әгъзалары:**

И.Ш.Бариев - Башкарма комитетның эшләр идарәчесе;

Н.Ә.Сәлимгәрәев - Актаныш районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча);

Л.Р.Сираева - Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары;

И.Р.Вахитов - муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе;

Д.М.Әнвәрова - Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары;

А.А.Корбангалина - финанс-бюджет палатасы рәисе;

Р.И.Мулюкова - икътисад бүлеге башлыгы;

Р.М.Шакирова - «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;

И.Р.Гобәева - социаль һәм агарту эшләре бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы;

Л.Ә. Вәлиев - яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы;

Р. Р.Шәрипов - «Коммунсервис» МУП директоры;

К.Н.Әхмәдгалиев -Актаныш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе;

М.Р.Мингазов - Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы;

Л.М.Хафизова -Яр Чаллы шәһәрендә Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең бүлек башлыгы урынбасары;

Д. М.Нәгыймов - «Теплосервис» ҖЧҖ директоры;

И.М.Муртазин - 103 янгын сүндерү-коткару бүлеге башлыгы, Актаныш янгын сүндерү-коткару гарнизоны башлыгы;

А. Р.Хәев - «Актаныш РҮХ» ДАССУ баш табибы;

Ф. Ә. Абдрахманов - Актаныш дәүләт ветеринария берләшмәсенең баш табибы.

**Башкарма комитет җитәкчесенә турыдан-туры буйсынмаган комиссия әгъзалары килешү буенча комиссия составына кертелә